**Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы**
**«Күтәмә авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге**
**гражданнары җыены**
**КАРАРЫ**

**Татарстан Республикасы**
**Чирмешән муниципаль районының**
**Күтәмә авыл җирлеге**
**составына керүче Күтәмә**
**торак пунктында гражданнар**
**җыены нәтиҗәләре турында**

**15.10.2025 ел** **№1**

«Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ номерлы Федераль законның 45,69 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында»2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә 2025 елның 15 октябрендә киләсе мәсьәлә буенча үткәрелгән гражданнар җыены нәтиҗәләре белән гражданнар җыены беркетмәсе төзелде: «2026 елда Чирмешән муниципаль районы Күтәмә авыл җирлегенең Күтәмә торак пункты территориясендә теркәлгән һәр балигъ булган кешегә 1000 сум күләмендә үзара салым кертүгә, 80 яшьтән өлкәнрәк гражданнардан, I төркем инвалидлардан, көндезге уку формасы буенча белем алучы студентлардан, Россия Федерациясе Кораллы Көчләре сафларында хезмәт итүче, Луганск халык республикасы һәм Донецк халык республикасы махсус операцияләрендә булган гражданнардан тыш һәм алынган чараларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча түбәндәге эшләргә җибәрү белән килешәсезме:

**- урамнарны тышкы яктырту челтәрләрен, трансформатор һәм башка подстанцияләрне һәм алар астындагы мәйданчыкларны, бүлү пунктларын һәм электр элемтәләрен тәэмин итү һәм электр энергиясен тапшыруны гамәлгә ашыру өчен билгеләнгән башка җайланмаларны ремонтлау** (Күтәмә торак пунктында урам яктырткычларын монтажлау, ремонтлау, алмаштыру);

**- торак пунктның башка территорияләрен төзекләндерү** (юл кырыйларын чабу, бензин, триммер өчен запас частьләр сатып алу һәм хезмәт күрсәтүләр өчен түләү, юлларны грейдерлау, кышкы вакытта урамнарны кардан чистарту, ягулык-майлау материаллары, трактор өчен запас частьләр сатып алу, Күтәмә торак пунктында тракторчыга исәпләнгән хезмәт хакы, югарыда күрсәтелгән эшләрне (хезмәт күрсәтүләрне) башкару өчен кирәкле материаллар сатып алу);

**- торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмиятле автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту** (вак таш, асфальт валчыклары сатып алу);

**- янгын куркынычсызлыгының беренчел чараларын тәэмин итү** (янгын гидрантларын ремонтлау)

Халык җыены нәтиҗәләре турында беркетмә нигезендә:

- сайлау хокукына ия җыенда катнашучылар исемлегенә гражданнар җыенының **387** катнашучысы кертелгән, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар җыенында катнашучылар саны **205** кеше.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучылар тавышлары түбәндәгечә бүленде:

«Әйе» позициясе өчен җыенда катнашкан **205** кеше тавыш бирде; «Юк» позициясе өчен беркем дә тавыш бирмәде.

Бәян ителгәннәр нигезендә, халык җыены карар итте:

1. Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Күтәмә авыл җирлеге составына керүче Күтәмә авылы торак пунктында халык җыены **булып узган**, халык җыены нәтиҗәләре - **чын** дип танырга.

2. Киләсе мәсьәлә буенча: «2026 елда Чирмешән муниципаль районы Күтәмә авыл җирлегенең Күтәмә торак пункты территориясендә теркәлгән һәр балигъ булган кешегә 1000 сум күләмендә үзара салым кертүгә, I төркем инвалидлардан, көндезге уку формасы буенча белем алучы студентлардан, Россия Федерациясе Кораллы Көчләре сафларында хезмәт итүче, Луганск халык республикасы һәм Донецк халык республикасы махсус операцияләрендә булган гражданнардан тыш һәм алынган чараларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча түбәндәге эшләргә җибәрү белән килешәсезме:

**- урамнарны тышкы яктырту челтәрләрен, трансформатор һәм башка подстанцияләрне һәм алар астындагы мәйданчыкларны, бүлү пунктларын һәм электр элемтәләрен тәэмин итү һәм электр энергиясен тапшыруны гамәлгә ашыру өчен билгеләнгән башка җайланмаларны ремонтлау** (Күтәмә торак пунктында урам яктырткычларын монтажлау, ремонтлау, алмаштыру);

**- торак пунктның башка территорияләрен төзекләндерү** (юл кырыйларын чабу, бензин, триммер өчен запас частьләр сатып алу һәм хезмәт күрсәтүләр өчен түләү, юлларны грейдерлау, кышкы вакытта урамнарны кардан чистарту, ягулык-майлау материаллары, трактор өчен запас частьләр сатып алу, Күтәмә торак пунктында тракторчыга исәпләнгән хезмәт хакы, югарыда күрсәтелгән эшләрне (хезмәт күрсәтүләрне) башкару өчен кирәкле материаллар сатып алу);

**- торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмиятле автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту** (вак таш, асфальт валчыклары сатып алу);

**- янгын куркынычсызлыгының беренчел чараларын тәэмин итү** (янгын гидрантларын ремонтлау) **кабул ителгән дип танырга.**

3. Халык җыены нәтиҗәләрен мәгълүмат стендларында һәм Чирмешән муниципаль районының рәсми сайтында Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә урнаштыру юлы белән игълан итәргә.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

**Гражданнар җыенында рәислек итүче**
**Татарстан Республикасы**
**Чирмешән муниципаль районы**
**Күтәмә авыл җирлеге башлыгы** **О.Н.Сайгушева**